СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2017 елның «14» декабреннән** **№31-180**

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 октябрендәге 299-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 7 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

7 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 14 пункт белән тулыландырырга:
«инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын үстерүгә, җайлаштырылган физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм итү»;

5) 19 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:
«муниципаль берәмлекне социаль-икътисадый үстерү стратегиясе проекты»;

33 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле35 пункт өстәргә: «муниципаль берәмлекне социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау»;

- 48 статьяның 1 өлешендә түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга:

«районның комплекслы социаль-икътисадый үсеш планнарын һәм программаларын үтәү турында хисаплар эшләүне тәэмин итә»;

«районның комплекслы социаль-икътисадый үсеш планнарын һәм программаларын үтәү турында хисаплар әзерләүне тәэмин итә»;

- 76 нчы статьяны түбәндәге эчтәлекле 12 нче өлеш белән тулыландырырга:

«Муниципаль берәмлек гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгели торган кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә»;

- 93 нчы статьяны түбәндәге эчтәлекле 4 нче өлеш белән тулыландырырга:

«Муниципаль берәмлек Уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнарының структурасын үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү (муниципаль берәмлек уставын федераль законнарга туры китерү очракларыннан, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлау вәкаләтләренең, вәкаләтләренең срогы, тәртибенең үзгәрүеннән тыш) Муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар имзалаган муниципаль район башлыгы вәкаләтләре тәмамланганнан соң үз көченә керә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән килгән көннән алып 7 көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**